ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында**

Казан шәһәре 2017 елның 15 мае

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Х. Кашапова мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Х. Кашапова Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен аңлату турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итте, аның белән мөрәҗәгать итүчегә «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 2 пункты һәм

2 нче кушымтаның 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятен карауга алудан баш тартылган.

Дәгъвалана торган нормалар белән 2016 елның 1 һәм 2 яртыеллыкларына күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен түләү айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 2 сум 70 тиен күләмендә билгеләнгән. Әлеге бәягә, гражданка Р.Х. Кашапова фикеренчә, «Казан шәһәренең бердәм исәп-хисап үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба — «Казан шәһәренең БИХҮ» ЖЧЖ) хезмәтләре өчен түләү кергән, аның күләме аларның күпфатирлы йортлары өчен айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 1 сум 23 тиен тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Конституция суды 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәләрдә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк дигән нәтиҗәгә килде.

Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге билгеләмәсен аңлату турындагы үтенечнамәдә гражданка Р.Х. Кашапова шуны күрсәтә: Татарстан Республикасы Конституция судына шикаятендә ул югарыда аталган нормаларның конституциячеллегенә алар күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләү агенты булмаган «Казан шәһәренең БИХҮ» ЖЧЖ тарафыннан исәп-хисаплар башкару хезмәтләре өчен түләүне кертүенә күрә дәгъва белдергән.

Аның фикеренчә, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә гражданнарның гомуми җыелышта тарифларны үзләре билгеләү хокукы булу җирле үзидарә органнары күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына теләсә нинди чыгымнар кертергә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми торган норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы дигәнне аңлатмый. Үз позициясен нигезләп, мөрәҗәгать итүче Монополиягә каршы

федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2016 елның 28 сентябрендәге ИП-05/13827 номерлы хатын күрсәтә, аның эчтәлегеннән, аерым алганда, «Жилищник-4» ИК эшчәнлегендә «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын бозу билгеләре ачыкланганлыгы аңлашыла, әлеге бозу күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләрен торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләү агенты булмаган «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖның исәп-хисап счетына кертергә мәҗбүр итүдә чагыла.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясына таянып, гражданка Р.Х. Кашапова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен дәгъвалана торган нормаларда шул исәптән алар билгеләгән күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына коммуналь хезмәтләрне үтәүче һәм түләү агенты булмаган оешма тарафыннан исәп-хисаплар башкару хезмәтләре өчен түләү керә алмаганга күрә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк дип танылу өлешендә аңлатуны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма, аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия затның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле

норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы һәм 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип шулай ук күрсәткән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы билгеләмәләр).

Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсенең дәлилләү өлеше эчтәлегеннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган хокукый җайга салу Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан торак законнары нормаларын гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән һәм, үзенең хокукый табигатеннән чыгып, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) торак урыннарны карап тоткан өчен хезмәт күрсәтү төрләре буенча түләү күләмен билгеләү хакында мөстәкыйль карар кабул итүгә хокукларыннан файдаланмаган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кагыла. Дәгъва белдерелә торган нормалар үзеннән-үзе күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, аны кертү шартлары һәм тәртибе турында карар кабул итү хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр күздә тотмыйлар. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шулай ук «Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 64 пункты эчтәлегеннән чыгып,

күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре, коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында идарәче оешма белән төзелгән шартнамә булганда, андый хезмәтләр өчен түләүне шул исәптән ресурслар белән тәэмин итүче оешма күрсәткән түләү агентлары яки банк түләү агентлары аша кертергә хокуклы, дип билгеләде.

Дәгъвалана торган нормаларны караганда, Татарстан Республикасы Конституция суды аларны гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыннарыннан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына нигезләмәләре белән физик затның тәэмин итүче алдындагы товарлар (эшләр, хезмәтләр) өчен түләү буенча акчалата бурычларын үтәүгә юнәлгән акчаларны түләү агенты тарафыннан түләүчедән кабул итү эшчәнлеген башкарганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салуның хокукый нигезләре беркетелгән «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан гына исәп-хисапларны башкару хезмәтләре өчен түләү керә алганлыгын күздә тота торган хокукый мәгънәсеннән чыгып бәяләгән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсенең эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нормаларына тулысынча таяна һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының күрәтелгән билгеләмәсе өстәмә тәфсилләүне яисә аныклауны таләп итми.

Гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсеннән аңлашылганча, аның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгате, асылда, 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәдә булдырылган хокукый позициядә билгелелек яки ачыклык булу-булмауга түгел, ә хокук куллану

практикасында дәгъвалана торган нормаларны интерпретацияләүгә бәйле. Шул ук вакытта «Казан шәһәренең БИХҮ» ЖЧЖ тиешле түләү агенты булып торамы-юкмы, торак урыннарны карап тоткан өчен түләүне хисаплаганда кулланыла торган тарифларның нигезле билгеләнгән булу-булмавы турындагы мәсьәләләр Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан махсус тикшерелмәде, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү өчен әлеге билгеләмәне рәсми аңлату таләп ителми.

2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.Х. Кашаповага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 16-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**